ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ МОНАЙ ТОРАК ПУНКТЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

2026 елда Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы Монай
авыл җирлегенең Монай авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү турында

11.11.2025 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2025 елның 1 ноябрендәге 7 нче номерлы карары нигезендә

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокклы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

«1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Йолдыз, Ленин урамнарына вак таш салу өчен вак таш сатып алу).

2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (тракторга асылмалы җайланма сатып алу);

3) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (фекаль насослар сатып алу);

4) узган елларның калган өлешләрен вак таш сатып алуга җибәрергә.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Монай авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге башлыгы _____________ Р.М.Кириллов
(имза) (имзаны киңәйтү)